ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.12.2021 Олы Кайбыч ав. № 533

2022 елга Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджетара мөнәсәбәтләр төзелгәндә исәпкә алына торган һәм муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла (күрсәтелә) торган муниципаль хезмәт күрсәтүләргә (эшләргә) норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда кулланыла торган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтләр күрсәтү һәм музейлар, китапханәләр, мәдәни - ял итү тибындагы учреждениеләр тарафыннан эшләр башкару нормативларын раслау турында» 2021 елның 22 сентябрендәге 893 номерлы һәм «Муниципаль учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган һәм Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (эшләрнең) якынча исемлеген раслау турында» 2015 елның 05 сентябрендәге 638 номерлы карары һәм Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2022 елга түбәндәгеләрне расларга:

2022 елга Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә норматив чыгымнар (1 нче кушымта);

2022 елга Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган муниципаль эшләргә норматив чыгымнар (2 нче кушымта).

2. «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә мәдәният учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның
«30» 12 № 533
карарына 1 нче кушымта

**2022 елга Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләргә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| т/б № | Учреждение исеме | Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив чыгымнар, сум | Елына хезмәт күрсәтү күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Музейлар | Музей предметларын, музей коллекцияләрен халыкка күрсәтү | 1290,72 | 1746 | берәмлек |
| 2 | Китапханәләр | Китапханә кулланучыларына китапханә, библиографик һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтү | 27 492,77 | 540 | берәмлек |
| 3 | Клуб тибындагы учреждениеләр | Кинофильмнар күрсәтү | 900,00 | 43 | берәмлек |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның
«30.» 12. №533
карарына 2 нче кушымта

**2022 елга Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәдәният учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган муниципаль эшләргә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| т/б № | Музейлар | Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив чыгымнар, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Китапханәләр Музейлар | тарихи-архитектура комплексының, тарихи мохитнең һәм ландшафтларның сакланышын һәм бөтенлеген тәэмин итү | - |
| | | музейларның экспозицияләрен (күргәзмәләрен) булдыру, күргәзмәләр оештыру | |
| | | музей предметларын, музей тупланмаларын реставрацияләү һәм консервацияләүне гамәлгә ашыру | |
| 2 | Китапханәләр Музейлар | документларны библиографик эшкәртү һәм каталоглар булдыру | 557 004,20 |
| | | китап һәйкәлләрен дә кертеп, китапханә фондын стабильләштерү, реставрацияләү һәм консервацияләүне гамәлгә ашыру | |
| | | китапханәләр фондларын цифрлаштыруны да кертеп, китапханәләр фондларын исәпкә алу, өйрәнү, һәм куркынычсызлыгын булдыру, физик яктан саклауны тәэмин итү | |
| 3 | Китапханәләр | клуб формированиеләре һәм үзешчән халык иҗаты формированиеләре эшчәнлеген оештыру | 39 163 300,00 |